| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**14.11.2023** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 3471** |

2024 елга «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары буенча норматив чыгымнарны раслау турында

2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273 номерлы Федераль законның 99 статьясы, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елга «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү мәктәп-интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнар (кушымта).
2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ әлеге карарның 1 пункты белән расланган гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.
3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы- җитәкчесе урынбасары Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Расланган
Зеленодольск муниципаль
районы Башкарма комитеты
2023 елның 10 ноябрендәге
3471 номерлы карары белән

**«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү мәктәп-интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап тотуга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасы тибы һәм төре | Территориаль урнашуы | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, бер елга сумнарда |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 107456 |
| | авыл җирлеге | 108826 |
| Гомуми белем бирә торган мәктәп-интернат | шәһәр җирлеге | 158070 |
| | авыл җирлеге | 162608 |